| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ШАЛТИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШАЛТЫ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 июля 2022г. с.Шалты № 40

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы
Шалты авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә ачык
тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибе
турында" 27.03.2020 № 110 нчы карары белән расланган
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 11 июнендәге 191-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә ачык тыңлаулар, җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибе турында" 27.03.2020 № 110 нчы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 статьяның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, мәгълүмат стендында һәм Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш»;

7 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Ачык тыңлауларда катнашучылар фикер алышуга чыгарылган проект буенча үз тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге сайты аша да, алдан ук ачык тыңлаулар үткәрү көнендә дә тапшырырга хокуклы.

Проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны урнаштыру һәм мондый проект экспозициясен үткәрү чорында гавами тыңлауларда

катнашучылар мондый проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы. :

1) Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының интернет-кабул итү сайты аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язмача яки электрон документ формасында.;

3) иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән.»;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 5 нче кушымтасында «язма рәвештә» сүзләреннән соң «яисә электрон документ формасында " сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 6 нчы кушымтасында "җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты» абзацыннан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Шалты авыл җирлеге Советының кабул ителгән карарларының дәлилләнгән нигезләнүе».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артымнан калдырам.

Шалты авыл җирлеге
Башлыгы, Совет рәисе З.Х. Фаткуллин